СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.05.2021 № 10/4
На № ________ от ____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары белән расланган «Җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 94 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары белән расланган «Җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктының икенче абзацында «җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр булдыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2.2 пунктының икенче абзацында «балыкчы һәм аучы йортлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) Нигезләмәнең 5.3 пунктын тулысынча төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Тукай муниципаль районы сайтында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — Ф.М. Камаев